**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

30.11.2019 г. Казань № 158од

Татарстан Республикасында Административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестрыннан өземтә яки соралган мәгълүматның булмавы турында белешмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 16 сентябрендәге 834 номерлы карары чыгу
һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентлары системасын эшләү турында» 2006 елның 16 июнендәге 310 номерлы карары үз көчен югалткан дип танылуга бәйле рәвештә, боерам:

1. 2015 елның 2 октябрендәге 01-02/685 номерлы Татарстан Республикасында Административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестрыннан өземтә яки соралган мәгълүматның булмавы турында белешмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (2016 елның 13 февралендәге 01-02/55 номерлы, 2016 елның 29 мартындагы 01-02/115 номерлы, 2017 елның 2 июнендәге 01-02/48 номерлы, 2018 елның 5 июнендәге 50 од номерлы, 2018 елның 21 сентябрендәге 105 од номерлы, 2019 елның 13 сентябрендәге 120 од номерлы боерыклар белән кертелгән үзгәрешләр белән), аны яңа редакциядә бәян итеп (кушымта итеп бирелә), үзгәреш кертергә.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр Р.И. Заһидуллин

Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгының
2015 елның 2 октябрендәге
01-02/685 номерлы боерыгы
белән расланган
(Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгының
елның
номерлы
боерыгы редакциясендә)

# Татарстан Республикасында Административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестрыннан өземтә яки соралган мәгълүматның булмавы турында белешмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасында Административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестрыннан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасында Административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестрыннан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә бирү буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте алучылар: кызыксыну белдергән органнар, оешмалар һәм физик затлар.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы (алга таба - Министрлык) тарафыннан кнгрсәтелә.

1.3.1. Министрлык урнашкан урын: Казан шәһ., Кремль ур., 16 йорт. Министрлыкның эш графигы: шимбә һәм якшәмбе көннәреннән кала көн саен, дүшәмбе - пәнҗешәмбе 9.00 дән 18.00 гә кадәр, җомга 9.00 дән 16.45 кә кадәр, төшке аш вакыты 13.00 дән 13.45 кә кадәр.

Мөрәҗәгатьләр дүшәмбе - пәнҗешәмбе 9.00 дән 18.00 гә кадәр, җомга 9.00 дән 16.45 кә кадәр кабул ителә.

Җәмәгать транспорты белән “Университет” тукталышына кадәр килергә:

10, 10а, 30, 35, 35а, 54, 63, 91 нче автобуслар;

2, 3, 5, 7, 8 нче троллейбуслар.

Бинага керү пропуск яки шәхесне ачыклаучы документ буенча.

1.3.2. Министрлыкның Җирле үзидарә өлкәсендә территориаль оештыру һәм тикшереп тору мәсьәләләре бүлегенең (алга таба – Бүлек) белешмәләр өчен телефоннары: (843) 223-06-50, 223-08-91, 237-67-88, 223-08-92.

1.3.3.Министрлыкның “Интернет” мәгълүмат һәм телекоммуникацияләр челтәрендә “Татарстан Республикасы рәсми порталы” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмати системасы составына кертелгән рәсми сайты (алга таба –

Министрлыкның рәсми сайты һәм “Интернет” челтәре) адресы: http://minjust.tatarstan.ru, электрон почтасы адресы: minjust@tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турындагы мәгълүматны түбәндәгечә алырга мөмкин:
1) Министрлык бинасында урнашкан, гариза бирүчеләр белән эшләү өчен дәүләт хезмәте турында текст рәвешендәге һәм күрсәтмә мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары аша;
2) “Интернет” челтәре аша:
Министрлыкның рәсми сайтында (http://www.minjust.tatarstan.ru);
Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatarstan.ru);
3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);
4) Министрлыкка язма рәвештә (шул исәптән, электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

1.3.5. Министрлыкның урнашкан урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, рәсми сайты адресы, шулай ук электрон почтасы турындагы мәгълүматлар Бүлек белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтына, “Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр реестры” дәүләт мәгълүмат системасына һәм Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталына урнаштырыла.

Министрлыкның гариза бирүчеләр белән эшләү өчен каралган бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырылган мәгълүмат дәүләт хезмәте күрсәтү турында әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3 - 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчасында) күрсәтелгән ике дәүләт телендәге мәгълүматларны үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 б., кертелгән үзгәрешләрне исәп алып);

“Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында” Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указы (алга таба – РФ Президенты Указы № 601) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2012, 7 май, басылып чыгу номеры: 0001201205070016);

“Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында” 2005 елның 7 декабрендәге 116-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12, 1052 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасында Административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестрының эчтәлеге һәм алып бару тәртибе турында нигезләмәне раслау турында” 2008 елның 29 сентябрендәге УП-460 номерлы Указы (алга таба – Нигезләмә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 9, 1200 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәп алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең

административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен рәсмиләштерү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары (алга таба – 880 номерлы карар) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, республиканың башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм төшенчәләр кулланыла:

Татарстан Республикасында Административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестры (алга таба – Реестр) – Татарстан Республикасындагы барлык административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктларның системалаштырылган исемлеге;

өземтә – Татарстан Республикасының административ-территориаль берәмлеге һәм (яки) торак пунктының реестрда булуын раслый торган язма рәсми документ;

белешмә – админ Татарстан Республикасының административ-территориаль берәмлеге һәм (яки) торак пунктының реестрда булмавын раслый торган язма рәсми документ;

техник хата – дәүләт хезмәтен күрсәткән чакта Министрлык тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе) кертелгән мәгълүматларның дөреслеккә туры килмәвенә китерә торган хата (хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны - дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкнең Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) шәһәр яки авыл җирлегендә Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыруның Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында" 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы карары белән расланган кагыйдәләрнең 34 пункты нигезендә булдырыган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офис);

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза дигәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү турында запрос аңлашыла (210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясының 1 пункты). Гариза әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган белешмәләрне күрсәтеп, ирекле формада төзелә.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләпнең аталышы | Стандартка булган таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтү яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Татарстан Республикасында Административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестрыннан өземтә яки соралган мәгълүматның булмавы турында белешмә бирү | Нигезләмәнең 10 пункты |
| 2.2. Башкарма хакимият органының исеме | Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 68 номерлы;<br>Нигезләмәнең 10 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Реестрдан әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә өземтә бирү.<br>Соралган мәгълүматның булмавы турында әлеге Регламентка 2 нче кушымта нигезендә белешмә бирү | Нигезләмәнең 10 пункты |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген дә исәпкә алып, дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документларны тапшыру | Гариза теркәлгән көннән соңгы 7 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары белән каралмаган.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документны тапшыру гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документны гаризада күрсәтелгән элемтә чарасын кулланып (почта аша, электрон адреска, факс буенча) тапшыру дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе рәсмиләштерелгән һәм теркәлгән көнне | Нигезләмәнең 10 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| (юллау) срогы | гамәлгә ашырыла. | |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарур һәм мәҗбүри булып торучы хезмәтләр күрсәтү өчен законнар яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле булган, гариза бирүче тарафыннан бирелергә тиешле документларның тулы исемлеге, гариза бирүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада да, аларны бирү тәртибе | Гариза (ирекле формада) түбәндәгеләрне эченә ала:<br>физик затлар өчен:<br>- фамилия, исем, әтисенең исеме;<br>- адрес (почта һәм (яки) электрон);<br>юридик затлар өчен:<br>- оешма исеме;<br>- адрес (почта һәм (яки) электрон).<br>Гариза кәгазь күчергечтә дә, электрон формада да бирелә ала. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар вәкаләтендә булучы һәм гариза бирүче аларны тәкъдим итү хокукына ия булган докуменларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада да, аларны тәкъдим итү тәртибе; әлеге документлар аларның вәкаләтләрендә булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма | Әлеге категориягә караган документларны тапшыру таләп ителми. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны алудан баш тарту өчен нигезләмәләрнең тулы исемлеге | Документларны кабул итеп алудан баш тарту өчен җирлек булып тора:<br>гаризада әлеге Регламентның 2.5 пунктында санап кителгән мәгълүматларның булмавы (шәхси мөрәҗәгать очракларыннан тыш) | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки аны күрсәтүдән | |

| | | |
|---|---|---|
| тору яки аны күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләмәләрнең тулы исемлеге | баш тарту өчен нигезләр юк. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төр түләү алуның тәртибе, күләме һәм нигезләмәләр | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмалар тарафыннан бирелгән (бирелә торган ) документ (документлар) турындагы мәгълүматлар | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.11. Хезмәт күрсәткәнгә, мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарур һәм мәҗбүри булган түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләмә | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтеннән файдалану турында гариза биргәндә яки шундый хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чиратта көтеп торуның максималь срогы | Дәүләт хезмәтен алырга тиешле кешенең кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтүендә максималь вакыт 15 минуттан артмаска тиеш.<br><br>Дәүләт хезмәтен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | РФ Президентының 601 номерлы Указның 1 пункты |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен, шул исәптән электрон формадагысын да, күрсәтүне сорап гариза бирүченең гаризасын теркәү | Гариза кергән көнне.<br>Гариза электрон формада ял көннәрендә кергән очракта - запрос кергән көннән соңгы эш көнендә. | |

| | | |
|---|---|---|
| срогы һәм тәртибе | | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналар һәм бүлмәләргә, гариза бирүчеләр көтеп утыра һәм кабул ителә торган урыннарга, дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризалар тутырыла торган урыннарга, һәр төрдәге дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге һәм тиешле гариза үрнәкләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртипләре турындагы күрсәтмә, текст рәвешендәге һәм мультимедия мәгълүматны урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә, шул исәптән әлеге объектларның инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвалидлар өчен уңайлы булуын тәэмин итүгә таләпләр | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга киртәләрсез керә алуы (бинага уңайлы керү-чыгу һәм бина чикләрендә уңайлы хәрәкәт) тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы күрсәтмә, текст рәвешендәге һәм мультимедия мәгълүмат гариза бирүчегә уңайлы урынга, шул исәптән инвалидларның мөмкинлекләре чикләнгәнлеген исәпкә алып урнаштырыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең уңайлылык һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгән чакта урындагы затлар белән үзара хезмәттәшлекләре саны һәм дәвамлылыгы, дәүләт хезмәте күрсәтелү эшенең барышы турында, шул исәптән мәгълүмати-коммуникация технологияләрен файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә, 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ статьясында каралган рәвештә дәүләт хзмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр | Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең сыйфат күрсәткечләре булып торалар:<br>1) документларны кабул итү һәм карау вакытлары саклану;<br>2) дәүләт хезмәте күрсәтелүнең нәтиҗәләрен алу вакытлары саклану;<br>3) әлеге Регламентның дәүләт граждан хезмәткәрләре (шикаятьләрнең Министрлыкның дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы урындагы затларының гомуми санына мөнәсәбәттә) тарафыннан бозылуына нигезле шикаятьләр булмау;<br>4) гариза бирүченең Министрлык белгечләре белән аралашулары саны:<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда - ике тапкырдан артык түгел (консультацияне исәпкә алмыйча); | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтелә торган күпфункцияле органнарында берничә дәүләт хезмәтен күрсәтү турында закрос нәтиҗәсендә гариза бирүченең сайлавы буенча башкарма хакимият органының терәсә-кайсы территориаль органында (экстерриториаль принцип) алу мөмкинлеге яки алып булмау (шул исәптән тулы күләмдә) | гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша юллаганда – бер тапкырдан артык түгел (консультацияне исәпкә алмыйча).<br>Гариза бирүче белән Министрлык белгеченең бер тапкыр үзара аралашуының дәвамлылыгы - 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең уңайлылык күрсәткечләре булып торалар:<br>1) бина һәм бүлмәләрнең җәмәгать транспорты килеп җитә торган урында булулары;<br>2) белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итеЛә торган бина һәм бүлмәләрнең җитәрлек санда булуы;<br>3) дәүләт хезмәте күрсәтүнең алымнары, тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү бердәм порталында тулы мәгълүмат бирелү;<br>4) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бина һәм бүлмәләрнең инвалидлар өчен уңайлы булулары;<br>5) инвалидларга биналарның инвалидлар өчен уңайлылыгына бәйле булмаган, аларга хезмәтләрне башкалар белән тигез дәрәҗәдә алырга комачаулый торган башка киртәләрне үтүдә булышлык итү.<br><br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү, дәүләт хезмәтен күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша гамәлгә ашырылмый.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турындагы мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан http://minjust.tatarstan.ru сайтында, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү бердәм порталында алынырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәтләрен экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы запрос буенча күрсәтү каралмаган. | |
| 2.16. Башка таләпләр, шул исәптән дәүләт хезмәтләрен экстерриториаль принцип | Гаризаны Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Интернет-кабул итү бүлмәсе (алга таба – Интернет- | |

| | | |
|---|---|---|
| буенча күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алган (дәүләт хезмәтләре экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм дәүләт хезмәтләрен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | кабул итү бүлмәсе) аша электрон формада бирү мөмкинлеге бар.<br>Гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatarstan.ru), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru) аша электрон документ формасында бирү мөмкинлеге гамәлгә ашырылганнан соң дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе электрон рәвештә тәкъдим ителә. | |

3. Административ процедуралар (гамәлләр) составы, аларны башкару эзлеклелеге һәм вакыты, аларны башкаруга карата куелган таләпләр, шул исәптән, административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада башкару үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама.

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән, электрон формада да, түбәндәге процедуралардан гыйбарәт:

гариза бирүчене консультацияләү, гариза бирүчегә ярдәм итү, шул исәптән, гариза язарга да;

мөрәҗәгатьне кабул итү һәм теркәү;

Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә һәм гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында хат әзерләү;

Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмәне гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында хат белән бергә юллау;

техник хаталарны төзәтү.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү һәм ярдәм күрсәтү

Гариза бирүче, дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алу максатыннан, Министрлыкка шәхсән үзе, почта аша, телефон аша, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы аша (яки) электрон почта аркылы мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә, аның мөрәҗәгатенең нинди ысул билән килүенә бәйле рәвештә, шәхсән үзе, телефон аша, электрон почта һәм (яки) хат белән, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать формасына һәм эчтәлегенә, рәсмиләштерү мәсьәләләренә кагылышлы мәсьәләләр буенча консультация бирә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать формасына һәм башка мәсьәләләргә кагылышлы консультация, шулай ук, күрсәтелгән ярдәм.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны Министрлыкка шәхсән үзе, почта аркылы, порталның интернет аша кабул итүе аркылы юллый.

Гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы аша бирелә ала.

3.3.2. Министрлыкның Оештыру эшләре һәм документлар әйләнеше бүлеге (алга таба - Оештыру бүлеге) белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм терки;

гаризаны документларны кабул итүдән баш тартырга әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигез булу-булмауга тикшерә. Тикшерү Бүлек белгече белән берлектә башкарыла.

Әлеге Регламентның 27 пунктында күрсәтелгән нигез булмаган очракта,гаризаны электрон формада “Электрон Хөкүмәт” Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының бердәм ведомоствоара электрон документлар әйләнеше системасында терки, аша (алга таба – электрон документ әйләнеше) Татарстан Республикасы юстиция министрына (алга таба – министр) юллый, әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигез була калса, документны гариза бирүчегә кире кайтара;

гаризаны электрон формада электрон документ әйләнеше аша Татарстан Республикасы юстиция министрына (алга таба – министр) юллый.

Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар булмаган гаризалар теркәлми.

Әлеге пункт билгеләгән процедура гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм министрга юлланган гариза.

3.3.3. Министр гаризаны карый һәм карау өчен министр урынбасарына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура гариза теркәлгән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: карар өчен министр урынбасарына юлланган гариза.

3.3.4. Министр урынбасары гаризаны карый һәм карар өчен Бүлек башлыгына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: карау өчен Бүлек башлыгына юлланган гариза.

3.3.5. Бүлек башлыгы җаваплы башкаручыны (алга таба – Бүлек белгече) билгели һәм гаризаны эшләү өчен аңа тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән көннән соңгы бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: эшләү өчен Бүлек белгеченә юлланган гариза.

3.4. Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмәне һәм гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтелү турында хатны әзерләү.

3.4.1. Бүлек белгече:

Реестрдан өземтә яисә сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә әзерли;

гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында хат проектын әзерли (алга таба – хат проекты) һәм аны, килештерү өчен, Бүлек башлыгына юллый.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гариза башкару өчен Бүлек белгеченә юлланган вакыттан алып ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Реестрдан өземтә яисә сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә һәм килештерү өчен Бүлек башлыгына юлланган хат проекты.

3.4.2. Бүлек башлыгы әзерләнгән Реестрдан өземтәнең яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмәнең дөреслеген тикшерә, гариза бирүчегә юлланасы хат проектын килештерә һәм аларны, килештерү өчен, министр урынбасарына юллый.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура Реестрдан өземтәнең яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмәнең һәм хат проектының Бүлек башлыгына килештерү өчен кергән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: килештерү өчен министр урынбасарына юлланган Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә һәм хат проекты.

3.4.3. Министр урынбасары Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә теркәлгән хат проектын килештерә һәм аны Бүлеккә юллый.

Процедура нәтиҗәсе: килештерелгән хат проекты, Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә.

3.4.4. Бүлек белгече килештерелгән хат проектын, Реестрдан өземтәне яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмәне имзалау өчен министрга юллый.

Әлеге Регламентның 3.4.3 – 3.4.4 пунктларында билгеләнгән процедуралар килештерү өчен министр урынбасарына Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә юлланган вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: имзалау өчен министрга юлланган хат проекты, Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә.

3.4.5. Министр Реестрдан өземтәгә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмәгә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүчегә юлланачак хатны имзалый.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура хат проекты, Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә министрга кул кую өчен юлланган вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: министр имзалаган Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә һәм гариза бирүчегә хат.

3.4.6. Бүлек белгече өземтәне әлеге Регламентка 3 нче кушымтага ярашлы рәвештә Реестрдан өземтәләр бирүне исәпкә алу журналында; белешмәне – әлеге Регламентка 4 нче кушымтага ярашлы рәвештә Реестрда сорала торган мәгълүматның булмавы турындагы белешмәләр бирүне исәпкә алу журналында терки һәм министр имзалаган хат белән Оештыру бүлегенә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмәне һәм хатны министр имзалаган көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: Оештыру бүлегенә юлланган теркәлгән Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә, шулай ук гариза бирүчегә хат.

3.5. Реестрдан өземтәне яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмәне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү турында хатны гариза бирүчегә юллау.

3.5.1. Оештыру бүлеге белгече дәүләт хезмәте күрсәтү турында министр имзалаган хатны терки, әлеге хат Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә белән бергә гариза язучы күрсәткән почта адресы буенча юллана яки, мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән булса, кулына тапшырыла.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура дәүләт хезмәте күрсәтү турында министр имзалаган хат белән Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә Оештыру бүлегенә юлланган соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә юлланган Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә, дәүләт хезмәте күрсәтелү турында хат.

3.6. Электрон формада алынган гаризаны карау.

3.6.1. Электрон формада алынган гаризалар әлеге Регламентның 3.3 – 3.5 пунктларында күрсәтелгән тәртиптә теркәлә һәм карала.

3.7. Техник хаталарны төзәтү.

Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмәне кабат рәсмиләштерү моңарчы тапшырылган Реестрдан өземтәдә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмәдә техник хата (язудагы хата, ялгыш басылу, грамматик яки арифметик хата) булган очракта башкарыла.

Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмәне кабат рәсмиләштерү ирекле формада язылып теркәлгән гариза нигезендә башкарыла. Мөрәҗәгать әлеге Регламентның 3.3.1 пунктында күрсәтелгән ысулларның берсе белән тапшырыла (мөрәҗәгать формасы әлеге Регламентның 5 нче кушымтасында тәкъдим ителә). Гаризага дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хаталы Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә (шәхсән үз кулына тапшырылганда), яки күчермәсе (почта аша яки электрон почтадан юллаганда) беркетелә.

3.7.1. Оештыру бүлеге белгече башкара:

мөрәҗәгатьне кабул итеп алу һәм теркәүне;

гариза бирүчегә документлар кабул ителгән көн күрсәтелгән, керү номеры куелган, дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты билгеләнгән мөрәҗәгатьнең күчермәсен тапшыру яки (теләге булса) почта аша яки электрон почта аша җибәрүне;

гаризаны электрон документ әйләнеше аша электрон формада министрга юллауны.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура мөрәҗәгать кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән, министрга юлланган гариза.

3.7.2. Министр мөрәҗәгатьне карый һәм карау өчен министр урынбасарына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать теркәлгән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: карау өчен министрурынбасарына юлланган мөрәҗәгать.

3.7.3. Министр урынбасары мөрәҗәгатьне карый һәм карау өчен Бүлек башлыгына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать теркәлгән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: карау өчен Бүлек башлыгына юлланган мөрәҗәгать.

3.7.4. Бүлек башлыгы Бүлек белгечен билгели һәм мөрәҗәгатьне үтәү өчен аңа тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать Бүлеккә юлланган мизгелдән бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: үтәү өчен Бүлек белгеченә юлланган мөрәҗәгать.

3.7.5. Бүлек белгече:

Реестрдан өземтә яки соралган мәгълүматның булмавы турында белешмә проектын кабат рәсмиләштерә;

гариза бирүчегә Реестрдан өземтә яки соралган мәгълүматның булмавы турында белешмә проектын кабат рәсмиләштерү турында хат проектын әзерли һәм килештерү өчен Бүлек башлыгына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать үтәү өчен Бүлек белгеченә юлланган көннән бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: килештерү өчен Бүлек башлыгына юлланган Реестрдан өземтә яки соралган мәгълүматның булмавы турында белешмә һәм хат проекты.

3.7.6. Бүлек башлыгы Реестрдан өземтә яки соралган мәгълүматның булмавы турында әзерләнгән белешмәнең дөреслеген тикшерә, гариза язучыга хат проектын килештерә һәм килештерү өчен министр урынбасарына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура Реестрдан өземтә яки соралган мәгълүматның булмавы турында белешмә һәм хат проекты килештерү өчен Бүлек башлыгына кергән көннән бер көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: килештерү өчен министр урынбасарына юлланган Реестрдан өземтә яки соралган мәгълүматның булмавы турында белешмә һәм хат проекты.

3.7.7. Министр урынбасары гариза язучыга аңа Реестрдан өземтә яки соралган мәгълүматның булмавы турында белешмә теркәлгән хат проектын килештерә һәм Бүлеккә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура проект Бүлек башлыгыннан кергән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: килештерелгән хат проекты, Реестрдан өземтә яки соралган мәгълүматның булмавы турында белешмә.

3.7.8. Бүлек белгече килешетерелгән хат проектын, Реестрдан өземтә яки соралган мәгълүматның булмавы турында белешмәне министрга юллый.

Процедура нәтиҗәсе: имзалау өчен министрга юлланган хат проекты, Реестрдан өземтә яки соралган мәгълүматның булмавы турында белешмә.

3.7.9. Министр Реестрдан өземтә яки соралган мәгълүматның булмавы турында

белешмәне һәм гариза язучыга хатны имзалый.

Әлеге Регламентның 3.7.8 - 3.7.9 пунктлары белән билгеләнә торган процедуралар Реестрдан өземтә яки соралган мәгълүматның булмавы турында белешмә һәм гариза язучыга хат проекты имзалау өчен министрга юлланган көннән бер көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: министр тарафыннан имзаланган Реестрдан өземтә яки соралган мәгълүматның булмавы турында белешмә һәм гариза язучыга хат.

3.7.10. Бүлек белгече кабат рәсмиләштерелгән өземтәне әлеге Регламентның 3 нче кушымтасына ярашлы рәвештә Реестрдан өземтәләр бирүне исәпкә алу журналында; кабат рәсмиләштерелгән белешмәне – әлеге Регламентка 4 нче кушымтага ярашлы рәвештә Реестрда сорала торган мәгълүматның булмавы турындагы белешмәләр бирүне исәпкә алу журналында терки һәм министр имза куйган хат белән бергә Оештыру бүлегенә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура кабат рәсмиләштерелгән Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә һәм гариза бирүчегә хат имзаланган көннән соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: теркәлгән һәм Оештыру бүлегенә юлланган Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә, шулай ук гариза бирүчегә хат.

3.7.11. Оештыру бүлеге белгече дәүләт хезмәте күрсәтү турында министр имзалаган хатны терки һәм Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә белән бергә гариза бирүче күрсәткән почта адресына яки, гаризада күрсәтелгән булса, кулына тапшырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура  министр Реестрдан өземтәне яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмәне һәм гариза бирүчегә хатны имзаланган көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: техник хаталары төзәтелгәннән соң гариза бирүчегә юлланган Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә.

## 4. Административ регламентның үтәлешен тикшерүдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү таләпләрен куючы Регламент нигезләмәләренең һәм башка норматив хокукый актларның саклануын һәм үтәлешен, шулай ук, җаваплы затларның карар кабул итүләрен агымдагы тикшерүдә тотуны Бүлек башлыгы яки Оештыру бүлеге башлыгы гамәлгә ашыра.

4.2. Агымдагы  тикшерү дәүләт хезмәте күрсәтү тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү рәвешендә гамәлгә ашырыла.

4.3. Тикшерүләр планга кертелгән һәм планнан тыш булырга мөмкин. Планга кертелгән тикшерүләр Министрлыкның ярты еллык һәм еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла. Планнан тыш тикшерү гариза бирүченең анык мөрәҗәгате нигезендә үткәрелә.

4.4. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең

хокукларын бозу очрагы ачыкланса, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган һәм гаепле дип табылган затлар, Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартылалар.

4.5.Дәүләт хезмәтләре күрсәтелүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан тикшерүдә тоту Министрлыкның дәүләт хезмәтләре күрсәтүдәге эшчәнлегенең ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүматлар алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең, шулай ук вазыйфаи затларның, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына, кылган гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүчеләр Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карарларына, кылган гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата судка кадәр Министрлыкка шикаять белдерүгә хокуклылар. Дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә министр кабул иткән карарларга карата белдерелгән шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән шул исәптән түбәндәге очракларда да мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең запросын теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3)мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар, мәгълүматлар яки гамәлләр кылу таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

7) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гариза бирүчедән документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда аларның булмавы һәм (яки) дөрес түгеллекләре күрсәтелмәгән, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган, яки дәүләт хезмәтен күрсәткән чакта кирәкле булган документлар яки мәгълүмат таләп итү, «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш.

5.2. Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Министрлыкның рәсми сайтыннан, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәй порталы яки Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып җибәрелә ала, шулай ук гариза бирүчедән шәхсән кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаять үз эченә түбәндәге мәгълүматларны алырга тиеш:

дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи затының исемен яки карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәткәренең исемен;

гариза бирүче - физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булса), яшәү урыны турында мәгълүматлар яки юридик затның исеме, урнашкан урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), гариза язучыга җавап җибәрелергә тиешле электрон почта (булса) адресы (адреслары) һәм почта адресы;

Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм кылган гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүматлар;

мөрәҗәгать итүченең Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карары һәм кылган гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәвенә дәлилләре.

5.4. Шикаятьне карау срогы - шикаять теркәлгән көннән 15 көне дәвамында. Ә Министрлыкның, Министрлыкның урындагы затының гариза бирүчедән документларны кабул итеп алудан баш тартуына, документта җибәрелгән хатаны төзәтүдән баш тартуына яки мондый төзәтмәләр кертелү вакыты бозылуга шикаять белдерелгән очракта - шикаять теркәлгән көннән биш эш көне дәвамында каралырга тиеш.

5.5. Гариза бирүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслаучы документлар (яки аларның күчермәләре) тапшырыла ала (алар булган очракта).

5.6. Шикаять гариза язучы тарафыннан шәхсән яки аның вәкаләтле заты тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1)шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре турында бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны төзәтү, гариза язучыга аларны алу Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында каралмаган акчаларны кире кайтару формаларында;

2)шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Гариза язучыга әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча язма формада һәм гариза язучының теләге буенча, электрон формада да, шикаять каралу нәтиҗәләре турында мотивлаштырылган җавап җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелүгә лаек дип танылган очракта гариза бирүчегә җавапта Министрлык тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән чакта табылган җитешсезлекләрне кичекмәстән төзәтү максатыннан гамәлгә ашырылачак гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук килеп туган уңайсызлыклар өчен гафу сорала һәм гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен алу максатыннан башкарылырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелүгә лаек түгел дип танылган очракта гариза бирүчегә җавапта мондый карар кабул ителү сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирдерү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.10. Шикаятьне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы ачыкланган очракта шикаятьләрне карау буенча урындагы зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына юллый.

Татарстан Республикасында
Административ-территориаль
берәмлекләр һәм торак пунктлар
реестрыннан өземтә яки соралган
мәгълүматның булмавы турында
белешмә бирү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасында

Административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестрыннан

өземтә

_________________ № ___________
(дата)

Әлеге өземтә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан
_____________________________________________________________________
(орган, оешма исеме яисә физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
бирелә,

аның нигезендә 20__ елның «____» _________ нә (на) Татарстан Республикасының Административтерриториаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестрында түбәндәге белешмәләрнең булуы раслана:

Бүлек:
_____________________________________________________________________
(бүлекнең исеме)
_____________________________________________________________________
(административ-территориаль берәмлекнең исеме һәм статусы)
_____________________________________________________________________

Татарстан Республикасы
юстиция министры

М.У. _____________ (имза) _________________ (Ф.И.Ә.и.)

Татарстан Республикасында
Административ-территориаль
берәмлекләр һәм торак пунктлар
реестрыннан өземтә яки соралган
мәгълүматның булмавы турында
белешмә бирү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасында Административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестрында соралган мәгълүматның булмавы турында белешмә

______________ № ___________
(дата)

Әлеге белешмә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан
____________________________________________________________________________
(орган, оешма исеме яисә физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
бирелә,
аның нигезендә
__________________________________________________
____________________________________________________________________________
турында сорала торган мәгълүматның 20__ елның «____» _________ нә (на) Татарстан Республикасында Административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестрында булмавы раслана.

Татарстан Республикасы
юстиция министры

_______________ ______________________
М.У. (имза) (Ф.И.Ә.и.)

Татарстан Республикасында

Административ-территориаль
берәмлекләр һәм торак пунктлар
реестрыннан өземтә яки соралган
мәгълүматның булмавы турында
белешмә бирү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына
3 нче кушымта

Татарстан Республикасында Административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестрыннан өземтәләр бирүне исәпкә алу
ЖУРНАЛЫ

| № п/п | Гаризаның министрлыкка кергән көне, керү номеры | Кызыксыну белдергән органнар, оешмалар һәм физик затларның исеме | Мөрәҗәгатьнең эчтәлеге | Реестрдан өземтә бирү көне, номеры |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |

Татарстан Республикасында
Административ-территориаль
берәмлекләр һәм торак пунктлар
реестрыннан өземтә яки соралган
мәгълүматның булмавы турында
белешмә бирү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына
4 нче кушымта

Татарстан Республикасында Административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестрында сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмәләр бирүне исәпкә алу
ЖУРНАЛЫ

| № п/п | Гаризаның Министрлыкка керү көне, теркәлү номеры | Кызыксыну белдергән органнар, оешмалар һәм физик затларның исеме | Гаризаның эчтәлеге | Исемлектән өземтә бирү вакыты, номер |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |

Татарстан Республикасында
Административ-территориаль
берәмлекләр һәм торак пунктлар
реестрыннан өземтә яки соралган
мәгълүматның булмавы турында белешмә
бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына

5 нче кушымта

(тәкъдим ителә торган форма)

Татарстан Республикасы
юстиция министры
Р.И.Заһидуллинга

____________________
(физик затлар өчен: ФИӘ.и. (соңгысы – булганда),
адрес (почта һәм (яки) электрон),

____________________________
юридик затлар өчен: оешманың исеме,
адрес (почта һәм (яки) электрон)

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Татарстан Республикасында Административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестрыннан өземтә биргән (яки соралган мәгълүматның булмавы турында белешмә биргән) чакта хата җибәрелгәнлеге турында белдерәм.

________________________________________________________
(бирелгән документ)
диелгән______________________________________________________________________.
Дөрес мәгълүматлар:
__________________________________________________________________________
Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.
Түбәндәге документларны терким:
1.
2.
Документның әзерлеге турында белдерүегезне үтенәм
____________________________________________________________________
(белдерү алымы)
______________________ (________________________________)
(дата) (имза) (имзаны тутырып язу)

Татарстан Республикасында
Административ-территориаль
берәмлекләр һәм торак пунктлар
реестрыннан өземтә яки соралган
мәгълүматның булмавы турында белешмә
бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына кушымта
(белешмәлек)

Татарстан Республикасында Административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестрыннан өземтә яки соралган мәгълүматның булмавы турында белешмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне тикшерүдә тотучы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы

| Вазыйфа, ФИӘ.и. | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | (843) 292-00-70 | minjust@tatar.ru |
| Министр урынбасары | (843) 292-00-53 | M.Ibyatov@tatar.ru |
| Җирле үзидарә өлкәсендә территориаль оештыру һәм тикшереп тору мәсьәләләре бүлеге башлыгы | (843) 223-04-96 | Gulnara.Kasymova@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Адрес | Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|---|
| 420014, Казан шәһ., Ирек мәйданы, 1 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының хокукый идарә башлыгы | (843) 264-76-25 | Andrey.Grevcov@tatar.ru |